**КАЗАН ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ**

**Казан шәһәре хакимиятенең мәгариф идарәсе Совет районы “Дәрвишләр бистәсенең балалар иҗаты үзәге” өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе**

| «КАБУЛ ИТЕЛДЕ» | «РАСЛЫЙМ» |
|---|---|
| ӨБМБУ “Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәге” методик киңәшмәсендә<br><br>Беркетмә №_1____________<br><br>« 29 » 08. 2022 ел. | «Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәге» директоры<br>______________ Гомәрова Ф.М.<br><br>Боерык №_ 32-ОД<br>«29» 08.2022ел. |

# Социаль-гуманитар юнәлештәге «Хыял» берләшмәсенең өстәмә гомумбеле бирү һәм гомумүстерү программасы

## программа 3 елга исәпләнгән 7-17 яшьлек балалар өчен

**Төзүче автор:**
**югары квалификацион категорияле өстәмә белем бирү педагогы**
**Хафизова Зөләйха Муса кызы**

**Казан, 2022 ел.**

**Информационная карта образовательной программы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | **Образовательная организация** | Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Центр детского творчества пос. Дербышки» Советского района г. Казани |
| 2. | **Полное название программы** | Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа «Хыял» |
| 3. | **Направленность программы** | Социально-гуманитарная |
| 4. | **Сведения о разработчиках** | |
| 4.1. | ФИО, должность | Хафизова Зулайха Мусиновна<br><br>педагог дополнительного образования высшей квалификационной категории |
| 5. | **Сведения о программе:** | |
| 5.1. | Срок реализации | 3 года |
| 5.2. | Возраст обучающихся | 7-17 лет |
| 5.3 | Характеристика программы:<br>- тип программы<br>- вид программы<br>- принцип проектирования программы<br>- форма организации содержания и учебного процесса | <br>дополнительная общеобразовательная программа<br>общеразвивающая<br>разноуровневая<br><br>групповая |
| 5.4. | Цель программы | создание условий для социализации творческой личности |
| 5.5. | Образовательные модули (в соответствии с уровнями сложности содержания и материала программы) | *Стартовый уровень*<br><br>*Базовый уровень* |
| 6. | **Формы и методы образовательной деятельности** | **Формы:** литературная гостиная, круглый стол, мастер-класс, занятие-игра<br>**Методы:** наглядные, практические, исследовательские |
| 7. | **Формы мониторинга результативности** | Беседа, опрос, практические задания, тестирование, исследовательский проект, участие в конкурсах |
| 8. | **Результативность реализации программы** | Входная и текущая диагностика, промежуточная аттестация обучающихся. Аттестация по завершении освоения программы. Участие в конкурсах различного уровня<br>-Международный литературный конкурс чтецов "Джалиловские чтения"- Медведев Н.(1место), Хабибуллина А.(2 место),Шигабиев И.(1 место) , 2020 г.<br>-Публикация в сборнике материалов |

| | | |
|---|---|---|
| | | всероссийской конференции "Алишевские чтения"- Маракиева Э., 2020<br>-Республиканский эпистолярный конкурс "Письмо писателю любимой книги" –Мингалиева К., Шигабиев И., дипломы участников, 2020<br>-Районный этап междунар. конкурса чтецов, посвященного Г.Тукаю – Медведева Н., 1 м. 2021 |
| 9. | **Дата утверждения и последней корректировки программы** | Протокол педагогического совета ЦДТ №1 от 29.08.2022<br>Приказ директора № 32-ОД от 29.08.2022<br>Изменения, внесенные в программу в 2022-2023 уч.году:<br>- изменения в нормативно-правовой базе<br>- корректировка целей и задач<br>- изменения в мониторинге качества освоения программы |
| 10. | **Рецензии**<br><br>**Внутренняя экспертиза** | Хафизова Т.Л., методист ЦДТ пос. Дербышки |

## Эчтәлек

**Комплекс основных характеристик программы:**

1. Аңлатма язуы………………………………………………………………………… 4 б.
2. Белем бирү программасының матрицасы ………………………………………………9 б.
3. Беренче уку елына укыту планы……………………………………………………..12 б.
4. Беренче уку елы программасының эчтәлеге....................................................................13 б.
5. Икенче уку елына укыту планы ……………………………………………………14 б.
6. Икенче уку елы программасының эчтәлеге ……………………………………………..16 б.
7. Өченче уку елына укыту планы ……………………………………………………16 б.
8. Өченче уку елы программасының эчтәлеге ……………………………………………18 б.

**Комплекс организационно-педагогических условий:**

11. Программаны үтәүдә педагогик-оештыру шартлары ……...........................................…..21 б.
12. Аттестация/контроль формасы һәм бәяләү материалы..………………………………..21 б.
13.Әдәбият исемлеге..............................................................................................................21 б.

**Кушымталар:**

Кушымта 1. Беренче уку елының календарь-укыту графигы…………….........................…23 б.
Икенче уку елының календарь-укыту графигы............................................27 б.
Өченче уку елының календарь-укыту графигы ………….....................……33 б.
Кушымта 2. Мониторинг качества освоения образовательной программы..........................46 б.
Кушымта 3. Диагностические и оценочные материалы…………………….......................... 50 б.

# Аңлатма язуы

“Хыял” әдәби-иҗат берләшмәсе программасы укучыларны әдәби иҗат нигезләренә өйрәтү өчен  төзелә. 7-17 яшьтәге укучыларга исәпләнелә. Өстәмә белем бирү системасында уку планының вариатив өлеше буларак тормышка ашырыла.

Берләшмәдә тәрбияләнүчеләр татар матбугаты, аңа бәйле юнәлешләр аша һөнәри юнәлеш алалар, татар матбугаты тарихы матбугат белән әдәбият бердәмлеге хакында мәгълүмат туплыйлар, массакүләм мәгълүмат чаралары белән даими кызыксыналар. 3 ел дәвамында укучылар үз ана телендә иркен аралашырга, иҗат итәргә өйрәнәләр, әдәби иҗатка тартылалар. Башлангыч сыйныфта укучыларның  авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә яза белүләренә ирешү өчен, сөйләм телен үстерү юнәлешендә даими эш алып барылырга тиеш. Бу максатларны тормышка ашыруда нәфис сүз, әдәби әсәрләр, матбугат  һәм халык авыз иҗаты әсәрләренең әһәмияте гаять зур. Әдәби иҗатка тартылу балаларны әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияләүгә дә булышлык итә. Программаның ***актуальлелеге*** шуның белән ассызыклана.

Программа разработана в соответствии со следующими нормативными документами:

- Федеральный закон РФ 273-ФЭ «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 г.
- Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 09 ноября 2018 N 196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам».
- Приказ Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации от 5 мая 2018 г. N 298  «Об утверждении профессионального стандарта "Педагог дополнительного образования детей и взрослых».
- Стратегия инновационного развития Российской Федерации на период до 2020 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 8 декабря 2011 г. № 2227-р.
- Федеральная целевая программа развития образования на 2016-2020 годы, утвержденная Постановлением Правительства Российской Федерации от 23 мая 2015 г. № 497.
- Концепция развития дополнительного образования детей до 2030 года. Утверждена распоряжением Правительства Российской Федерации от 31 марта 2022 г. № 678-р.
- Санитарно-эпидемиологические требования к организации воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи - СП 2.4.3648-20 от 1.01.2021г (Постановление Главного государственного  санитарного врача РФ от 28.09.2020 №28).
- Стратегическая инициатива "Новая модель системы дополнительного образования", одобренная Президентом Российской Федерации 27 мая 2015 г.

-Устав МБУДО «Центр детского творчества пос.Дербышки» Советского района г. Казани.
-Положение о дополнительных общеобразовательных общеразвивающих программах

“Хыял” әдәби-иҗат берләшмәсенә йөрүче укучылар төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда актив катнашалар.

Программа 3 елга исәпләнелгән. Уку елы буенча шөгыльләрне үткәрү  тәртибе:
Төркемнәрдәге укучылар саны: 15 бала
Бер елга сәгатьләр бүленеше:
1 нче уку елы – 144 сәг.
2-3 уку елы – 216 сәг.

“Хыял” программасы үзләштерелү ягыннан һөнәри юнәлешле. Программа өчен материал туплаганда, иң элек әсәрнең укучыны  ни дәрәҗәдә кызыксындыра алуы (үзенең эчтәлеге белән балага якын булуы), сөйләм телен баетуга ярдәме, тәрбияви әһәмияте искә алынды.  Шулай ук балаларның психологик үсеше һәм яшь үзенчәлекләренә зур игътибар бирелде.

“Хыял” әдәби иҗат берләшмәсе программасы дәрестән тыш эшчәнлекнең бер юнәлеше буларак тәкъдим ителә. Түгәрәк эчтәлеге һәм укыту методлары буенча укучыларның дәресләрдә алган белем-күнекмәләрен тулыландыру, һөнәр сайлауга әзерләү, иҗади эшчәнлеккә кызыксыну тәрбияләүдә, укыту һәм тәрбиянең бергәлеген ныгытуда зур

роль уйный. Балаларның иҗатка тартылуы, татар матбугатын, иҗат алымнарын өйрәнү, анализлау да игътибарга алынды. Программаның яңалыгы шунда: кече яшьтән максатчан рәвештә укучылар иҗатка тартыла, фәнни-эзләнү эшчәнлеге буенча күнекмәләр ала. Теоретик белемнәрне системалы рәвештә гамәлдә кулланырга өйрәнә.

Берләшмә утырышларын кызыклы, мавыктыргыч итеп үткәрү, балаларның сәләтен, танып-белү активлыгын үстерү өчен, дидактик һәм иҗади күнегүләр, уеннар кулланыла. Бу алым материалны үзләштерү дәрәҗәләрен ачыкларга, шуның белән бергә алган белемнәрен, осталык һәм күнекмәләрен ныгытырга, үстерергә булыша.

## Программаның максаты һәм бурычлары

**Максат:**

***үз халкының тарихын, матбугатын, зыялы шәхесләрен камил белгән, конкуренциягә сәләтле иҗади шәхес тәрбияләү.***

Бурычлар:

***<u>Белем бирү бурычы:</u>***

- Татар матбугатын, жанр төрлелеген, бу өлкәдә эшләүче шәхесләр хезмәтен өйрәнү;
- Берләшмәдә укучыларны журналист эшчәнлегенең принциплары, журналист һөнәренең үзенчәлекләре, матбугатка, ТВ, радиога кагылышлы башка һөнәрләр хакында белемнәр белән коралландыру.
- Журналистика тарихын, аның үсеш этапларын өйрәнү.
- Социология һәм журналист осталыгы нигезләрен өйрәнү.
-Журналист осталыгы күнекмәләре, коммуникатив компетенция формалаштыру, һөнәр сайлауга беренче адымнар ясау, һөнәри юнәлеш булдыру.
- Мәктәпнең басма матбугатын чыгару буенча практик белем һәм күнекмәләр булдыру.

***<u>Белем һәм күнекмәләрне камилләштерү бурычы:</u>***

- Укучыларның иҗади сәләтләрен төрле яклап үстерү, гомуми күзаллауларын киңәйтү.
- Әдәби иҗатка, журналистикага кагылышлы теоретик белемнәрне тирәнәйтү, фәнни яктан анализлау, ныклы күнекмәләр булдыру һәм аларны гамәли яктан тормышта дөрес кулланырга өйрәтү.
- Әдәби, фәнни, публицистик характердагы текстларны анализлау; стилистик сурәтләү чараларын кулланып, төрле жанрда иҗат итү; алынган тема буенча телдән чыгыш ясый белү күнекмәләрен булдыру; фәнни-эзләнү эшчәнлегенә тарту.

***<u>Программаның тәрбияви бурычы:</u>***

-Актив тормыш позициясе, бергә аралашып эшләү күнекмәләре булдыру.
- Күпмилләтле социумда милләтара мәдәният, толерантлык формалаштыру;
- Иҗади омтылыш уяту, һәр яктан камил булган шәхес тәрбияләү;
- Җәмгыять тормышында әһәмиятле роль уйнаучы журналист һөнәре хакында күзаллау формалаштыру.
-Матбугатка, ММЧна, җәмгыять эшчәнлегенең бер төре булган журналистикага кызыксыну уяту.
- Үз-үзеңне тоту һәм сөйләм культурасы тәрбияләү.

## Белем бирү этаплары һәм көтелгән нәтиҗәләр

***1. Белем бирүнең беренче уку елында көтелгән нәтиҗәләр:***

Башлангыч этапта төп бурыч укучыны матбугат һәм әдәбият дөньясына алып керү, аларны иҗади мавыктыру, иҗади эшчәнлеккә кызыксыну уяту, “Хыял” берләшмәсенең

утырышларына йөрүгә ихтыяҗ тудыру. Шуңа күрә дә белем бирү беренче елдан ук мавыктыргыч, укучыларның сәләтләрен ачардай, талантларын үстерердәй булырга тиеш. Үзенең кечкенә генә иҗат җимешен күрсә, укучының иҗатка омтылышы арта.

***Беренче уку елы азагында укучылар белергә тиеш:***

-Яшь хәбәрчегә куелган таләпләр;

-Массакүләм мәгълүмат чаралары (укучыларның яшь үзенчәлегенә туры килгән);

- Массакүләм мәгълүмат чараларда күтәрелгән проблемалар;

- Массакүләм мәгълүмат чараларда жанр төрлелеге;

-Төрле жанрда иҗат итү күнекмәләре;

-Аудитория каршында чыгыш ясау, үз фикереңне дәлилли белү;

***Беренче ел азагында берләшмәдә тәрбияләнүчеләр алган белем һәм күнекмәләр:***

-Гомуми кулланыш нормалары һәм кыйммәтләре күзлегеннән кешеләрнең эш-гамәлләрен, тормыш ситуацияләрен бәяләү;

-Текстны “эмоциональ кичерү”, үз фикереңне белдерү;

-Башка кешеләрнең хисләрен аңлау, кешенең хәленә керү, аңа теләктәшлек белдерү;

-Укылган мәкалә, әсәр геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү.

-Иҗат итү күнекмәләре булдыру.

***Беренче ел азагында берләшмәгә йөрүчеләрдә тәрбияләнергә тиешле сыйфатлар:***

-Яшь хәбәрчегә куелган сыйфатларны яхшы белү, үтәү;

-Түбәндәге кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү: коллективта үзара аңлашу, ихтирам, милли үзаң, яхшылык, түземлелек, табигатьне саклау, туган ил белән горурлану, гаилә кадерен белү һ.б.;

-Иҗатка карата кызыксыну формалаштыру;

-Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү;

-Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оешытру;

-Укытучы җитәкчелегендә дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү;

***2. Белем бирүнең икенче-өченче уку елында көтелгән нәтиҗәләр***:

Бу этапта укучыларда журналист һөнәренә бәйле төп белем һәм күнекмәләр булдырыла. Алар мөстәкыйль рәвештә төрле дәрәҗәдәге ММЧларны укып кабул итә, анализлый, үз фикерен әйтә беләләр. Төрле матбугат чаралары белән хезмәттәшлек итәләр. Фәнни эзләнү эшенә куелган таләпләрне үзләштерәләр, фәнни гамәли конференцияләрдә чыгыш ясыйлар.

***Белем бирүнең икенче-өченче уку елында укучылар белергә тиеш:***

-Фәнни-методик әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү;

-Төрле дәрәҗәдәге фәнни-эзләнү эшеләренә таләпләрне үтәү;

-Тиешле мәгълүматны табу, эшкәртү, әдәби редакцияләү;

-Геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу;

-Укылган яки тыңланган текстны анализлау;

-Дәрестән тыш эшчәнлек һәм тормыш ситуацияләре буенча төрле жанрда иҗат итү;

-Журналистның һөнәри этикасы;

-Әдәби-публицистик жанрлар;

-Күренекле журналистлар иҗаты;

-Телевидение тапшыруларының үзенчәлеге;

-Радиотапшыруларда сөйләм осталыгы.

**Берләшмәдә тәрбияләнүчеләр алган белем һәм күнекмәләр:**
-Мәктәпнең вакытлы матбугат органын булдыру, аны укыту-тәрбия процессында куллану;
-Укучыларның программада каралган теоретик һәм гамәли күнекмәләрне үзләштерүләре;
-Үз фикерләрен дәлилли, карашларын нигезли белү, телдән һәм язма сөйләм осталыгына өйрәнү;
-Мәгълүмат ташкынында югалып калмау, төрле чыганаклардан мәгълүмат эзли, таба, эшкәртә белү;
-Иҗади фикер йөртүче, көндәшлеккә сәләтле, социаль актив булу;
-Тема сайлау, сайлаган теманы ачу, дәлилләү, редакцияләү;
-Әдәби редакцияләү алымнарын белү;

**Берләшмәгә йөрүчеләрдә тәрбияләнергә тиешле сыйфатлар:**
-Иҗади омтылыш;
-Үз эшчәнлеген планлаштыра һәм оештыра белү;
-Сөйләм культурасына ия булу;
-Гомумкешелек һәм милли мәдәни кыйммәтләргә омтылыш;
-Социаль җаваплылык;
-Парлап һәм күмәк эшләү.

***Программа буенча белем бирү нәтиҗәлелеген тикшерү***

Программа буенча буенча белем бирү нәтиҗәлелеген тикшерү берничә этапта башкарыла: гадәти, яртыеллык, йомгаклау;

Гадәти (агымдагы) контроль берләшмә утырышларында һәр укучының эшчәнлеген, иҗади үсешен күзәтү, юнәлеш бирү, аның нәтиҗәләрен анализлау формасында уздырыла;

Яртыеллык контроль билгеле бер темаларны узгач, укучыларның иҗади эшләре (шигырь, мәкалә, репортаж, интервью һ.б.) формасында уздырыла;

Йомгаклау тикшерүе һәр уку елы азагында иҗади остаханә, әдәби кичә, иҗади лаборатория, шигъри сабантуй, кызыклы очрашулар клубы һ.б. формаларда берләшмәнең ачык утырышы итеп уздырыла.

**Программаның азагында контроль юнәлешләре:**
- Берләшмәнең үз газетасын (җыентыгын) чыгару.
- Массакүләм мәгълүмат чараларда чыгыш ясау.
- Район, республика матбугатында язмаларын бастыру.
- Фәнни эзләнү эшләрен яклау, җыентыкларда бастыру.
- Проект эшләре, презентацияләр әзерләү.

***Белем бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре*** : укучыларның туган телдә камил сөйләшүе, иҗади осталык серләрен белүе, төрле жанрларда иркен иҗат итүләре, үзләре күргәнне-белгәнне башкаларга да җиткерү теләге, төрле конкурсларда катнашуга омтылыш.

***Укучыларның белем-күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәләре өч төрдә бәяләнә:***
- ✓ Югары
- ✓ Уртача
- ✓ Түбән

**Бу программаның үзенчәлеге шунда** – ул әзерлек дәрәҗәләре, белемнәре, мөмкинлекләре төрле булган балаларның мәнфәгатьләрен истә тотып төзелгән.

Программаны төзегәндә төрле дәрәҗәдәге критерияләр исәпкә алынды:

## Беренче уку елына укыту-тематик планы

| № | Тема | Барысы | Теория | Практика | Формы организации занятий | Контроль, аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш педагогик-психологик диагностика | 2 | 0 | 2 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Әңгәмә | Сораштыру<br>Иҗади эш |
| 2. | Матбугатта заман сулышы. | 18 | 10 | 8 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш |
| 3. | Яшь иҗатчыга куелган таләпләр | 20 | 10 | 10 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш |
| 4. | Матбугат һәм тел бердәйлеге. | 20 | 10 | 10 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 5. | Халык авыз иҗаты әсәрләре – илһам чыганагы | 40 | 20 | 20 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку<br>Театрлы уен | Әңгәмә<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 6. | Иҗади осталык мәктәбе. | 40 | 20 | 20 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 7 | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 8 | Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| Барысы | | 144 | 72 | 72 | | |

## Беренче уку елы программасының эчтәлеге

**1.** Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Кереш педагогик-психологик диагностика

**2. Матбугатта заман сулышы:**

Бүгенге җәмгыять һәм матбугат бәйләнешен анализлау. Публицистик стильгә куелган таләпләрне өйрәнү. Журналистика һәм аның ролен ачыклау. Бүгенге көн проблемалары яссылыгында татар матбугаты.

- Газета эшчәнлеген күзәтү, анализлау кебек гамәли күнекмәләрне үстерү.

Жанр төрләре: мәкалә, отчет, репортаж, интервью, сораштыру, рецензия, корреспонденция, очерк, фильетон, эссе һ.б.

- Һәр жанрга хас үзенчәлекләрне өйрәнү, теоретик белемнәрне гамәлдә куллану
- Интервью алуның шартлары, төрләре
- Рольле уенар “Редакциядә бер көн” һ.б.
- Балалар матбугатында жанр үзенчәлекләре

**3. Яшь иҗатчыга куелган таләпләр**
- Газетаның төзелеше, макет, верстка;
- Материалның формасы, күләме;
- Полосаның төзелеше;
- Материалны бирү алымнары;
- Беренче бит. Аның типлары;
- Фоторәсемнәрнең функциясе;
- Басманың типологиясе;
- Чыгу ешлыгы, тираж, күләм, формат, адресат;
- Массакүләм мәгълүмат чараларына экскурсия;
- Мәктәп газеталарының төрләре һәм типлары;
- Журналист осталыгы;

**4. Матбугат һәм тел бердәйлеге.**
- Сөйләм культурасы чагылышын анализлау.
- Матбугатта басылган язмаларга күзәтү ясау.

**5. Халык авыз иҗаты әсәрләре – илһам чыганагы**
- Халык авыз иҗатының гүзәл үрнәкләрен укучыларның иҗади сәләтен үстерүдә куллану. Халык авыз иҗаты әсәрләренең юнәлеше буенча теоретик белемнәрне арттыру, иҗат итү буенча гамәли күнекмәләр булдыру. Татарстанда чыгучы журналларда халык авыз иҗаты чагылышын өйрәнү.
- Бүгенге көндә балалар өчен чыгучы журналлар, аларда балалар фольклорының чагылышын анализлау.
- Халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр белән әдәби кунакханә. Интервью өчен сораулар әзерләү, әңгәмә кору осталыгына ирешү.

**6. Иҗади осталык мәктәбе.**
-- Төрле формада иҗади отчет әзерләү. Иҗади сәләтне үстерердәй эш төрләре табу.
- Үзара хезмәттәшлек. Әдәби тәнкыйть. Күмәк эшләр.
- Жанр төрләре: мәкалә, отчет, репортаж, интервью, сораштыру, рецензия, корреспонденция, очерк, фильетон, эссе һ.б.
- Һәр жанрга хас үзенчәлекләрне өйрәнү, теоретик белемнәрне гамәлдә куллану
- Интервью алуның шартлары, төрләре
- Рольле уен “Редакциядә бер көн”
- Балалар матбугатында жанр үзенчәлекләре
- “Мин сокланган каләм остасы”, “Минем иҗади табышларым”.... иҗади эшләр.

**7.** Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация.

**8.** Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация

## Икенче уку елына укыту-тематик планы

| № п/п | Наименование разделов и тем | Количество часов | | | Формы организации занятий | Контроль, аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Барысы | Теория | Практика | | |
| 1 | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү Күзәтү | Сораштыру Иҗади эш |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Викторина | Тест |
| 2 | Журналистикада жанр төрлелеге. Сөйләм культурасы | 90 | 50 | 40 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 3 | Әңгәмә һәм аның төрләре | 30 | 10 | 20 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 4 | Текстның композициясе | 30 | 20 | 10 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Театрлы уен | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 5 | Башисем сайлау, төзәтү. | 20 | 11 | 9 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 6 | Яшь иҗатчыга куелган таләпләрне үзләштерүне дәвам итү | 40 | 20 | 20 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 7 | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Тест |
| 8 | Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Тест<br>Иҗади эш |
| **Итого** | | 216 | 114 | 102 | | |

## ПРОГРАММАНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ
## II нче уку елы

1. Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре.

**2. Журналистикада жанр төрлелеге. Сөйләм культурасы**

-Журналистикада жанр төрләре, аларга куелган таләпләр
- Сөйләм культурасының төп аспектлары белән таныштыру.
- Сөйләмдә сүзнең төп роле һәм әһәмияте турында аңлату.
- Телнең функциональ стильләре турында аңлату.
-Матур әдәбият стиле һәм гади сөйләм теленең үзенчәлекләре белән таныштыру.
-Образлы сурәтләү чаралары, стилистик фигуралар һәм тропларның үзенчәлекләрен, аларны сөйләмдә дөрес кулланунын әһәмиятен аңлату.

**3. Әңгәмә һәм аның төрләре**

- Әңгәмә һәм аның төрләре, әңгәмә кору үзенчәлекләре белән таныштыру.
- Практик дәресләрне оештыру
- Рольле уен “Танышыйк та дуслашыйк”

**4. Текстның композициясе**

- Әсәрдә эчтәлек һәм форма бөтенлеге. Эчтәлек, жанр таләпләре. Эчтәлеккә, нинди адресатка багышлануына карап текстның күләме.
- Текстның бөтенлегенә ирешү, сөйләм оештыру кагыйдәләрен үтәүнең әһәмияте.

- Композиция, сюжет төшенчәләренә редактор карашы. Бу төшенчәләрнең матур әдәбият, журналистик әсәрләрдә, матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре иҗатында үзенчәлекле чагылышы.
- Сәхифә, рубрика. Кисәк, бүлек, бүлекчә, параграф, пункт, кызыл юл төшенчәләре. Газет, журналда текст төзелеше, сәхифә, рубрика.
- Текстта иллюстрация материалларын (сурәт, фото, клише һ.б.) урнаштыру, төзәтү. Рәсем асты тексты. Бу эштә кимчелекләр, аларны бетерү юллары.

**5. Баш исемен сайлау, төзәтү.**

- Баш исеменең эчтәлек белән форманы бәйләүче чара, текстның аерылгысыз кисәге булуы.
- Баш исеменә төп таләпләр: эчтәлек белән туры бәйлелек, конкретлык, диккать җәлеп итүчәнлек, яңалык, аһәңлек һ.б.
- Әдәбият, жанр төренә карап баш исеме. Текст бөтенлеген саклаучы чара буларак баш исеме. Тулаем әсәргә, аның өлешләренә куела торган баш исемнәренең нисбәте. Нисбәтнең бозылуына китергән сәбәпләр, кимчелекләрне бетерү юллары Газетта рубрика, баш исеме, башасты һәм башөсте исемнәре. Радио, телевидениедә тапшыруны исемләү мәсьәләсе.
- Баш исемен табу, сайлау, камилләштерү - иҗади эш. Авторга ярдәм алымнары. Баш исеме чыганаклары: төрле стиль сүзе, сүзтезмә (синтагма), фразеологизмнар, мәкаль, әйтем, гыйбарә, канатлы берәмлек, цитатлар һ.б., аларны үзгәртү мөмкинлекләре. Калыплашкан баш исемнәре, алардан котылу юллары.

**6. Яшь иҗатчыга куелган таләпләрне үзләштерүне дәвам итү**

- Яшь иҗатчыга куелган таләпләр
- Иҗади эшчәнлек төрләре
- Шигырь язу, редакцияләү

**7. Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация**.

8. **Уку елы нәтиҗәләре буенча арадаш аттестация**

## Өченче уку елына укыту-тематик план

| т/п № | Тема | Сәг.саны | Теория | Практика | Формы организации занятий | Контроль, аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре. | **2** | **1** | **1** | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Әңгәмә | Сораштыру<br>Тест |
| 2 | Бүгенге матбугатка күзәтү | 10 | 5 | 5 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Тест<br>Иҗади эш |
| 3 | Әдәби-мәдәни яңалыклар | 10 | 4 | 6 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 4 | Матбугат һәм тел бердәмлеге | 14 | 4 | 10 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Рольләргә бүлеп уку | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 5 | Тел-стиль чараларын анализлау | 14 | 10 | 4 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 6 | Татар матбугатының үсеше | 22 | 12 | 10 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 7 | Халык авыз иҗаты үрнәкләре | 30 | 10 | 20 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Әңгәмә<br>Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 8 | Яшь иҗатчыга куелган таләпләрне үзләштерүне дәвам итү | 50 | 20 | 30 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 9 | Фәнни эзләнү эшенә әзерлек | 40 | 12 | 28 | Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Иҗади эш<br>Тест |
| 10 | Иҗади осталык мәктәбе | 20 | 10 | 10 | Эчтәлек өстендә эш<br>Эзләнү<br>Күзәтү<br>Викторина | Сораштыру<br>Әңгәмә<br>Иҗади эш |
| 11 | Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация. | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Сораштыру<br>Иҗади эш |
| 12 | Программаны үзләштерү аттестациясе | 2 | 1 | 1 | Эзләнү<br>Күзәтү | Тест<br>Иҗади эш |
| **Барысы** | | **216** | **90** | **126** | | |

**Өченче уку елы программасының эчтәлеге**

1. **Кереш дәрес. Куркынычсызлык кагыйдәләре.**

**2. Бүгенге матбугатка күзәтү**

- Бүгенге җәмгыять һәм матбугат бәйләнешен анализлау. Публицистик стильгә куелган таләпләне белүне камилләштерү. Журналистика һәм аның ролен ачыклау.Бүгенге көн проблемалары яссылыгында татар матбугаты.
- Газета эшчәнлеген күзәтү, анализлау кебек гамәли күнекмәләрне үстерү.

**3. Әдәби-мәдәни яңалыклар.**

- Практик эш төрләрен арттыру. Төрле юнәлештәге газеталарга күзәтү ясау. Кайбер газета редакцияләренә экскурсиягә бару. Театр, музейларга сәяхәт. Күргәннәрең хакында төрле жанрда иҗат итү күнекмәләрен ныгыту.

Бүгенге көндә балалар өчен чыгучы журналлардагы яңа сәхифәләрне күзәтеп бару.

**4.Матбугат һәм тел бердәйлеге.**

- Тел-стиль чаралары, аларның матбугатта чагылышын анализлау.
- Матбугатта басылган язмаларга күзәтү ясау.

**5.Тел-стиль чараларын анализлау.**

- “Иҗат белән ялкынланып яшик”. Төрле язмалардагы тел бизәкләү чараларын анализлау.
- Төрле каләм ияләренең иҗат портретларын тудыру.
- “Ялкын”да яңа сәхифәләр, аларның тел бизәлешен күзәтү, төрле алымнар белән иҗат итү.

**6.Татар матбугатының үсеше**

- Матбугатта яшьләр темасының чагылышын төрле басмалар үрнәгендә анализлау.
- Бүгенге көндә чыгучы шәхси газеталарны күзәтү, юнәлешләрен билгеләү.
- Аерым газеталарга күзәтү ясап, нәтиҗәләрне бергәләп ачыклау.

**7. Халык авыз иҗаты әсрләре – илһам чыганагы**

- Халык авыз иҗатының гүзәл үрнәкләрен укучыларның иҗади сәләтен үстерүдә куллану. Халык авыз иҗаты әсәрләренең юнәлеше буенча теоретик белемнәрне арттыру, иҗат итү буенча гамәли күнекмәләр булдыру. Татарстанда чыгучы журналларда халык авыз иҗаты чагылышын өйрәнү.
- Бүгенге көндә балалар өчен чыгучы журналлар, аларда балалар фольклорының чагылышын анализлау.
- Халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр белән әдәби кунакханә. Интервью өчен сораулар әзерләү, әңгәмә кору осталыгына ирешү.

**8. Яшь иҗатчыга куелган таләпләрне үзләштерүне дәвам итү.**

- Матбугаттагы һәм әдәби жанрларны белүне үстерү.
- Әдәби иҗатка куелган таләпләрне гамәлдә куллану.
- Үз язмаңны редакцияләү күнекмәләрен үстерү.

**9.Фәнни эзләнү эшенә әзерлек.**

- Фәнни эзләнү эшенә куелган таләпләрне гамәлдә куллану.
- Төрле иҗади конкурсларда, конференцияләрдә катнашуга әзерлек.

**10.Иҗади осталык мәктәбе.**

- Төрле формада иҗади отчет әзерләү. Иҗади сәләтне үстерердәй эш төтләре табу.
- Үзара хезмәттәшлек. Әдәби тәнкыйть. Күмәк эшләр.

**11. Беренче яртыеллык буенча арадаш аттестация.**

**12. Программаны үзләштерү аттестациясе**

**Программаны үтәүдә педагогик-оештыру шартлары**

**-Укыту кабинете**
**-Парталар, урындыклар**
**-ИКТ** (компьютер, принтер, интерактив такта, электрон текстлар)
-Электрон таблицалар
-

**Аттестация/контроль формасы һәм бәяләү материалы**

- кереш психологик-педагогик диагностика
- агымдагы диагностика
- арадаш аттестация
- йомгаклау аттестациясе

**Бәяләү материалы**

-- тестлар
- әңгәмә сораулары
- анкета
- дидактик материаллар

-иҗади эшләр

**Әдәбият исемлеге**

**Норматив документлар:**

- Указ Президента Российской Федерации от 7 мая 2018 г. № 204 «О национальных целях и стратегических задачах развития Российской Федерации на период до 2024 года».
- Указ Президента Российской Федерации от 29 мая 2017 г. № 240 «Об объявлении в Российской Федерации Десятилетия детства».
- Федеральный закон РФ 273-ФЭ «Об образовании в Российской Федерации» от 29 декабря 2012 г.
- Постановление Правительства Российской Федерации от 31 октября 2018 г. № 1288 «Об организации проектной деятельности в Правительстве Российской Федерации».
- Распоряжение Правительства Российской Федерации от 6 июля 2018 г. N 1375, об утверждении Плана основных мероприятий до 2020 года, проводимых в рамках Десятилетия детства.
- Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 09 ноября 2018 N 196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам».
- Приказ Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации от 5 мая 2018 г. N 298 н «Об утверждении профессионального стандарта "Педагог дополнительного образования детей и взрослых».
- Стратегия инновационного развития Российской Федерации на период до 2020 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 8 декабря 2011 г. № 2227-р.
- Федеральная целевая программа развития образования на 2016-2020 годы, утвержденная Постановлением Правительства Российской Федерации от 23 мая 2015 г. № 497.
- Концепция развития дополнительного образования детей, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 4 сентября 2014 г. № 1726-р.
- Стратегия развития воспитания в Российской Федерации на период до 2025 года, утвержденная Распоряжением Правительства Российской Федерации от 29 мая 2015 г. № 996-р.
- Концепция общенациональной системы выявления и развития молодых талантов на 2015-2020 годы (утверждена Президентом Российской Федерации 3 апреля 2012 г. № Пр-827) и комплекс мер по ее реализации (утвержден Правительством Российской Федерации 27 мая 2015 г. № 3274п- П8).
- Стратегическая инициатива "Новая модель системы дополнительного образования", одобренная Президентом Российской Федерации 27 мая 2015 г.

**Файдаланылган әдәбият исемлеге:**


1. Әсәдуллин А.Ш. Татар сөйләме / А.Ш.Әсәдуллин. – Казан: Тарих,2002.- 256 б.
2. Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнүреш йолалары. Казан тат.кит.кәшр., 1995.
3. Гарифуллин В.З. Журналистның ижади эшчәнлеге, В.З.Гарифуллин. — Казан: КДУГ. 2004.— 156 6
4. Гарифуллин В.З. Язар сүзең булса... – Казан, 2000. – 204 б.
5. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. - Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. - 144 б.
6. Габдулхаков В.Ф. Риторика. – Казань, Магариф, 2004
7. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. Казан: Мәгариф нәшр. 2005
8. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: Мәкальләр җыелмасы:3 томда/ 2 нче басма. – Казан, 2010.
9. Исәнбәт Н. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. - –азан, 1984.
10. Казан театрлары. Альбом. К., 2011.

**11.** “Мәгариф” журналы.
**12.** “Сабантуй” газетасы..
**13.** “Ялкын” журналы
**14.** Н.Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 2003.
**15.** Мияссарова И.Х., Гарифуллина Ф.Ш., Гильфанова Ә.Ә. “Кем тизрәк, өлгеррәк”, укытучылар, ата-аналар һәм урта педагогик уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы,. – Казан,2010
**16.** Нуриев Г.С. Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге – Казан: Мәгариф, 2009. – 199 б.
**17.** Спирина Н.А. Журналистика в школе: программа, материалы к занятиям. – Волгоград: Учитель, 2011.-207 б.
**18.** Галләмова Р. Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, сынамышлар. – Казан: Гыйлем, 2014. – 80 б.
**19.** Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Конференция (Казан, 17 май, 2005 ел) материаллары: докладлар һәм тезислар. – Казан: ун-тет нәшр., 2005. – 144

Интернет- ресурслар :
**20.** ММЧ хокукларын яклау сайты. URL: http://www.mmdc.ru/
**21.** "Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе сайты. URL: http://www.tat.tnv.ru